ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.11.2021 г. с.Ямбулатово № 2

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Кызыльяр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 7 декабренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Кызыльяр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 6800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:
- Кызыльяр авылында Лесная урамы буенча юлга вак таш салу
«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Кызыльяр авылы Лесная урамы адресы буенча урнашкан 28нче йорт янында гражданнар җыенын 09.00 сәгатьтә үткәрергә.
4. Халык җыенын оештыручы итеп Ямбулат авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә .

5.Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы А.Н.Макаров